Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга, Казаклар авыл торак пунктларында узган

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020елның 17 ноябре

№ 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга, Казаклар авыл торак пунктларындагы гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Казаклар авыл торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, уку йортларының көндезге бүлекләрендә торып укучы студентларыннан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре, гражданнарның үзара салымын 400 сум күләмендә кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   -Олы Елга, Сорочьи Горы авылларындагы суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
   - авыл җирлеге торак пунктларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
   - Олы Елга авылында Мөхәммәтгали урамындагы юлларны ремонтлауга (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә, эшләнгән эшләр өчен түләүгә);
   -Казаклар авылында Яр буе урамында (вак таш сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, вак ташны җәюгә, эш өчен түләүгә);
   -Сорочьи Горы авылының Прикамская, Пролетарская, Садовая-1,Садовая-2 урамнарында (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә, эшләнгән эшләр өчен түләүгә);
   - авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);
   - Казаклар авылында Горная урамындагы инеш аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылы зираты территориясен  киртәләүгә (тотып алуга) (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылындагы Молодежная урамында тышкы суүткәргеч салуга (220 см тирәнлектә траншея казуга, 63 мм диаметрлы торбаларны сузуга, траншеяны күмүгә, янгын гидранты урнаштыруга);

- Казаклар авылында контейнер мәйданчыклары  ясауга һәм җиһазландыруга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Казаклар авылында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 5 данә контейнер сатып алуга.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы,  25 йорт; Казаклара вылы, Үзәкурам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йортһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципальрайонының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштыру юлы белән  игълан итәргә (халыкка җиткерергә).

4.Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Садриев